Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге Советы

**КАРАР №10**

Шумково авылы 19.07.2024

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Шумково авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләренең бер өлешен җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү һәм күрсәтелгән мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу буенча Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Шумково авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Шумково авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль негамәлгә ашыру вәкаләтләренең берөлешен җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү һәм күрсәтелгән мәсьәләне норматив-хокукый җайга салу буенча Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга.

2. Балык Бистәсе муниципаль районы җирлегенең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тапшыру турында килешүләр төзүне тәкъдимитәргә, аның предметы күрсәтелгән мәсьәләне норматив-хокукыйҗайга салу буенча җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүдән гыйбарәт.

3. Вәкаләтләрнең берөлешен башкаруны тапшыру Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан ел саен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджет ара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында: Шумково авылы, Үзәк урам, 4 йорт; Олы Укмас авылы, Үзәк урам, 42 йорт; Хутор авылы, Яшьләр урамы, 5 йорт; Әшнәк-Качкалак авылы, Югарыгы урам, 5 йорт һәм Татарстан Республикасы

Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге башлыгы урынбасары ____________ Моталлапов Н.Н.